Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының
бишенче чакырылышының икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

16 октябрь, 2025 ел № 13

Махсус хәрби операция ихтыяҗлары өчен муниципаль мөлкәтне тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 3 октябрендәге 1745 номерлы, «Икътисад өлкәсендә махсус чара турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 30 апрелендәге 616 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 25 июлендәге 213 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәнең 2 өлеше нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. 33836 номерлы хәрби часть дивизионы командиры урынбасары, өлкән лейтенант Борһанов Илдус Риф улына махсус хәрби операция зонасында ихтыяҗлар өчен муниципаль мөлкәтне әлеге карарга кушымта нигезендә милеккә тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы (Иванова С.Н.) әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән мөлкәтне тапшыруны гамәлгә ашырырга.

3. «Махсус хәрби операция ихтыяҗлары өчен муниципаль мөлкәтне тапшыру турында» 2025 елның 26 февралендәге 393 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарының 1 нче кушымтасын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов